ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм “Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 4, 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы беренче өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 1; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 4, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче җөмләдә “мәҗбүри басылып чыгу көне” сүзләреннән соң “яки Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) йә” сүзләрен өстәргә;

2) икенче җөмләне төшереп калдырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ

номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның беренче өлешендә “газеталарында бастырып чыгару” сүзләреннән соң “яки Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) йә” сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әгәр әлеге статьяда башкасы каралмаган булса, Татарстан Республикасы законнары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан имза салынганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.”;

б) икенче өлештә “Республика Татарстан” һәм “Ватаным Татарстан” газеталарында” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) дүртенче өлештә “аларга имза салган көннән 10 көн эчендә” сүзләрен “федераль норматив хокукый актлар нигезендә” сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2014 елның 25 декабре
№ 131-ТРЗ